Латыйпов, Х. "Агач ялгышуларны яратмый" / Х. Латыйпов; [әңгәмәдәш] З. Нигъмәтуллина // Ирек мәйданы. – 2023. – №36 (14 сентябрь). – Б. 12.







**Татарстан һәм Россия Рәссамнар берлекләре әгъзасы, танылган рәссам, керамика, агач ую сәнгате остасы һәм талантлы шагыйрь Хәмит ЛАТЫЙПОВ иҗатына сокланмаган кеше юктыр! Хәмит Нәҗип улы быел да Чаллыда оештырылган "Ел рәссамы" бәйгесенең "Сынлы сәнгать" номинациясендә беренчелекне яулады. Әбит бу останың хезмәтләре нибары ике гади эш коралы — пычак һәм өтерге белән башкарылган.**

# "АГАЧ ЯЛГЫШУЛАРНЫ ЯРАТМЫЙ"

**— Хәмит абый, иң беренче агач эшләнмәгез үк милли тематикада булгандыр дип күз аллана...**

— Иң яраткан иҗат эшләремнең берсен 1975 елда Уфа сәнгать училищесының II курсында укыганда ясаган идем. Габдулла Тукай иҗатына таянып, "Шүрәле" панносын иҗат иттем. Бүген бу хезмәтемдәге Шүрәле миңа киләчәккә юл таба алмаган кавемебезне хәтерләтә. Киләчәккә юл, минемчә, ана теленең бар уку йортларында, мәктәпләрдә күбрәк укытылуы белән бәйле. Хәзерге татар балаларының рус телендә гәпләшүе — аяныч күренеш. Үз ана телендә югары белем ала алмаячакларын алар инде яхшы белә, шуңа аларны чит тел җәлеп итә. Зур милләтебезнең үз телендә укыта торган университеты, институты булмау аңлашылмый...

1977 елда "Суга бару" панносын иҗат иттем. Калган хезмәтләрем дә милләтем мәдәнияте белән бәйле. Олы тарихыбызны барлап, "Җиңүче", "Туган ил турында җыр" кебек паннолар, сувенирлар ясадым, уен коралларыбызны искә алып, кубызда, курайда, гармунда уйнаучыларны сурәтләдем.

**— Иҗатыгызда табигать, урман күренешләре күп.**

— Чөнки балачак хатирәләрем Башкортстанның матур табигате белән бәйле. Аның яме, андагы урманнар һәм чишмәләр җыры, кошлар сайравы — мине яшәргә өметләндергән рухый кыйммәтләр дияр идем. Ул авазларны гомерем буе сагынып яшим! Моны туган авылсыз калган кеше генә аңлыйдыр. Кызганыч, мин үскән Буләр авылы җир йөзендә юк инде. 1970 еллар азагында аны гигантомания бетерде. Ул чорда кечкенә авылларны таркатып, андагы халыкны зуррак салаларга, үзәкләргә күчерделәр. Әмма бу вакыйгалар рухый фаҗигагә китерде. Чөнки кешеләрнең күбесе күченгән җирләренә ияләшә алмады. Безнең Буләрдә кибет, ферма, башлангыч мәктәп бар иде. Авылыбыз урман-басуларга бай җирдә урнашкан. Шул 45 ләп йортлы авылыбызны бик тә сагынып, гел кайтып йөрдем. Аның һәр өе, урамы хәзер дә төшемә керә. Элекке авылдашлар белән һәр җәй саен Буләрдә җыелабыз... Туган җир тарта.

Туган ягым хозурлыгын, декоратив тәлинкәләр иҗат иткәндә дә, гел күз уңында тоттым. Тәлинкә фоннарын милли чигүләребез, каюлы читекләребезне хәтерләткән, милләтебезгә генә хас сызым-бизәкләр белән бизәттем. Агачтан уюның билгеле бер кагыйдәләрен искә төшерер идем: агач ялгышуларны яисә артык кисеп бозуларны яратмый.

Милләт уңышы төшенчәсенә әйләнеп кайтсак, милләт балалары ике белемгә: үз тарихыбызга һәм ана телебезгә омтылсалар гына, милли үзенчәлекләребезне саклап калачакбыз. Милли сынлы һәм гамәли сәнгатебезне пропагандаларга кирәк. Узган көздә "Хәзинә" милли сәнгать галереясындагы "Туган җирдә" дигән күргәзмәмә ата-аналар — балаларын, укытучылар укучыларын алып килде. Балаларның, яшүсмерләрнең эшләнмәләрем, картиналарым белән теләп танышуын, миңа да бихисап сораулар яудыруын күрү күңелемә бер никадәр өмет өстәде.

**Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.**

герже районы Мордывый авылында яшәүче Гүзәл